РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru


27.02.2019 № 3

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Уставы нигезендә Юлбат авыл башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга (1 нче кушымта ).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/ulbat бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы: Т.Р. Шәмсиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитетының 27.02.2019 № 3 карарына кушымта №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару Тәртибе.

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Юлбат авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Юлбат авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3. Юлбат авыл башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

3.1. Юлбат авыл башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Юлбат авыл башкарма комитетының карар проекты әзерләнә.

3.1.Юлбат авыл башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Юлбат авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибенә кушымта

____________20___ел хисап чорына
(беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел))
Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүматлар

| Хезмәткәрләр категориясе | хисап чоры өчен, хезмәткәрләр саны | хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар. (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |